**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2016 елның 30 сентябре** **№ 53**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 21 апрелендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә::

«2.2. Муниципаль хезмәткәргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмнәрдә һәм тәртиптә айлык өстәмә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,

муниципаль район Советы рәисе П. Н. Лоханов